КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1048

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2015 ел, 16 февраль, 95 нче; 2019 ел, 8 февраль, 83 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1254 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта:

алтынчы абзацта «һәм телевидение сәнгате», «телевизион тапшырулар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«журналистика һәм телевидение сәнгате өлкәсендә – массакүләм мәгълүмат чараларында документаль һәм публицистик эшләр, телевизион тапшырулар, артистлар, режиссерлар, операторлар, рәссамнар, сценарийлар язучылар, телевидение алып баручылары эше өчен;»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

35 яшькә кадәрге аерым язучылар;

яшьләр коллективлары (70 процентын 35 яшькә кадәрге яшьләр тәшкил итә торган авторлар төркеме).»;

7 пунктта «конкурс игълан ителгәннән соң килә торган 15 гыйнварга кадәр» сүзләрен «19 декабрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә лаек булган затларга (авторларга, коллективларга) «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты» исеме бирелә, бер диплом һәм бер лауреат тамгасы тапшырыла.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә әсәрләр һәм эшләр тәкъдим итү өчен барлык материаллар utalents.ru сайтында презентация формасында, мәкаләләр, рецензияләр, фотосурәтләр һ.б. рәвешендә, шул исәптән расланган күчермәләр рәвешендә урнаштырыла:

а) әдәбият өлкәсендә – әсәрләр pdf форматында тапшырыла;

б) сынлы сәнгать, музыка, хореография, театр, цирк, кино сәнгате өлкәсендә – сценарийлар, нота материалы, фильмнарның аудио, видеоязмалары, фотосурәтләр, репродукцияләр һәм башка иллюстрация материалы рәвешендә;

в) журналистика өлкәсендә – массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, телерадиотапшырулар;

г) фән, җитештерү һәм эшмәкәрлек өлкәсендә – күргәзмәләрдә катнашу турында модельләр, каталоглар, материаллар, проспектлар һәм башка материаллар рәвешендә;

д) мәгариф өлкәсендә – уку-укыту планнары һәм программалары, методик материаллар;

е) иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендә – тәкъдим итүче оешмаларның үтенечнамәләре һәм тасвирнамәләре.»;

15 – 16 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Оешма эшен тәкъдим итү турындагы үтенечнамә белән бергә оешмалар тарафыннан түбәндәгеләр тапшырыла:

а) оешманың эш тәкъдим итү турындагы коллегиаль карары (коллегия, утырыш, сәнгать советы һәм гыйльми совет беркетмәсе һ.б.);

б) тәкъдим ителгән эшнең кыскача аннотациясе һәм аның иҗтимагый танылуы турында төп мәгълүмат;

в) җәмәгатьчелек күзәтүе өчен әсәрне тәкъдим итү датасы һәм урыны турында белешмә кәгазе;

г) эшнең киң җәмәгатьчелек тарафыннан танылуын дәлилли торган материаллар (мәкаләләр, рецензияләр, фотосурәтләр һ.б. рәвешендә, шул исәптән расланган күчермәләр рәвешендә);

д) авторның эшне иҗат итүгә керткән өлешен характерлый торган материал.

Барлык материаллар М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга әсәр яки эш тәкъдим итүче оешма тарафыннан раслана.

Бер оешма тарафыннан берничә әсәр һәм эш тәкъдим ителгәндә, аларның һәрберсенә аерым үтенечнамә языла.

16. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим итү буенча барлык материаллар utalents.ru сайтында тутырыла. Өстәмә материаллар 420021, Казан шәһәре, Г.Тукай урамы, 113 нче А йорт, 2 нче бүлмә адресы буенча җибәрелә. Элемтәгә керү өчен телефоннар: 8 (843) 205-00-02, 8 (843) 205-00-06, 8 (843) 205-00-08, e-mail: Molodezh.Centr@tatar.ru.»;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты турындагы нигезләмәдә:

5 пунктның икенче абзацында «2 бөтен 3 тән ун тавышы» сүзләрен «утырышта катнашучылары санынан ике бөтен өчтән ун тавыш» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим итү буенча барлык материаллар utalents.ru сайтында тутырыла. Өстәмә материаллар 420021, Казан шәһәре, Г.Тукай урамы, 113 нче А йорт, 2 нче бүлмә адресы буенча җибәрелә. Элемтәгә керү өчен телефоннар: 8 (843) 205-00-02, 8 (843) 205-00-06, 8 (843) 205-00-08, e-mail: Molodezh.Centr@tatar.ru.»;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составында:

Комитет составыннан Д.Х.Салиховны, Д.А.Таюрскийны, А.Г.Тормасовны, Д.И.Фәттаховны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

«В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (ИИХИ)» югары һөнәри белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эшләр буенча проректоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Игорь Измаилович Бикеевны (килешү буенча);

«Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) рәисе Ркаил Рафаил улы Зәйдуллинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Андреевна Кондратьеваны;

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтына караган гомуми һәм этник социология кафедрасы доценты, социология фәннәре кандидаты Ольга Александровна Максимованы;

Тимур Җәүдәт улы Сөләймановның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Комитет рәисе»;

Гөлнара Ильяс кызы Сабированың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе әгъзасы, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин